ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» мая 2024 ел № 151

«2024 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.02.2024 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 26.02.1997 елның 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 21.09.2022 елның 647 номерлы Указы, «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20.10.2022 елның 1122 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2024 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.02.2024 елның 52 номерлы карарының 5 пунктындагы 5.4 пунктчасына өстәргә:

«махсус хәрби операциядә катнашу зонасында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның балаларын, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның балаларын ял итү һәм сәламәтләндерү юллама бәясенең 100%».

2. 2024 елга Әгерҗе муниципаль районында яшьләр ялын оештыру программасының 2 бүлегенең 3 пунктындагы 2 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне өстәргә:

«МБУ «Ровесник» яшүсмерләр клубы».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х.Салихов**